| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО ПРОМЫШЛЕННОСТИ И ТОРГОВЛИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СӘНӘГАТЬ ҺӘМ СӘҮДӘ МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

10.09.2024

___________ Казан ш. №_178-ОД_____

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.11.2023 ел, №221-ОД боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.11.2023 ел, № 221-ОД боерыгын Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясына туры китерү максатларында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының «Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибен раслау турында» 20.11.2023 ел, № 221-ОД боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә ресурслары министрлыгы тарафыннан администрацияләнә торган түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта:

2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гражданинның, шәхси эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау – күрсәтелгән Федераль закон нигезендә аларның түләү йөкләмәсен үтәүдән азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурычлар өлешендә;»;

3 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) бюджетка түләүләр түләүче затны банкрот дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты кабул итү;»;

5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча әҗәтләрне түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә, шул исәптән аны түләттерүнең билгеләнгән срогы үтүгә бәйле рәвештә дә;»;

6 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) «Башкару эше турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләтүчегә кире кайтарганда, әгәр бурыч барлыкка килгән көннән бурычлыга карата бөлгенлек турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләр күләменнән артмаса, башкаручы суд приставы тарафыннан башкару эшен тәмамлау турында карар чыгару (бөлгенлек) банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен биш елдан артык вакыт узган булса;»;

3 пунктның «в» пунктчасында:

дүртенче абзацта «3 пунктчасында» сүзләрен «2 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «4 пунктчасында» сүзләрен «7 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

сигезенче абзацта «(әлеге Тәртипнең 2 пунктының 6 пунктчасында күрсәтелгән очракта)» сүзләрен «(әлеге Тәртипнең 2 пунктының 3, 6 пунктчаларында күрсәтелгән очракларда, шулай ук әлеге Тәртипнең 2 пунктының 7 пунктчасында күрсәтелгән очракта)» сүзләренә алмаштырырга;

тугызынчы абзацта «6 пунктчасының өченче абзацында» сүзләрен «3 пунктчасында» сүзләренә алмаштырырга;

11 пунктның икенче җөмләсен төшереп калдырырга;

13 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия утырышы йомгаклары буенча, әлеге Тәртипнең 13 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы уздырылган көннән алып 10 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану турында карар проекты әзерләнә. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында Комиссия карары Комиссия утырышын уздырган көннән алып 5 эш көне эчендә түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:»;

13 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Акт ике нөсхәдә төзелә һәм утырышта рәислек итүче һәм Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.»;

14 пунктта «имзаланган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 16 пункт өстәргә:

«16. Әлеге Тәртипнең 13 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта, Комиссия утырышы беркетмәсендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтүгә өметсез дип тану өчен нигезләр булмау турындагы мәгълүмат чагылдырыла. Беркетмә утырышта рәислек итүче һәм Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана һәм министрга хәбәр итү өчен җибәрелә.».

2. Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының юридик бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары -
министр О.В. Коробченко